
Бүгенге санда:



Бәйрәм бизәкләре. 2-3 битләр


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 13 май 2015 ел

№ 34 (10563)


**14 майга һава торышы:** аязучан болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көньяктан, 1-2 м/с; температура көндез +19°C, төнлә +12°C

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### ПРАЙМЕРИЗЛАР БАШЛАНДЫ

"Бердәм Россия" партиясе Нурлат җирле бүлекчәсендә эчке партия тавыш бирүләре башланып китте. Аларның беренчеләре кичә Яңа Иглай һәм Урта Камышлы авыл җирлекләрендә халыкның зур активлыгы белән үтте. Авылларда праймеризлар 22 майга кадәр 26 мәйданчыкта үтәчәк, Нурлатта эчке партия тавыш бирүе 26 майга билгеләнгән.

### ЧИРАТТА – ҮСЕМЛЕКЛӘРНЕ САКЛАУ

Район буенча кичәге көнгә язгы чәчү эшләре барлык мәйданнарның 72 процентында тәмамланган. Хуҗалыкларда чөгендер чәчү төгәлләнү ягында, язгы бодай, кукуруз, көнбагыш, күпьеллыклар чәчү дәвам итә. Язгы чәчү белән бервакытта үсемлекләрне саклау буенча эшләр башланды. "Сөләйманов Ә.И" КФХсы һәм "Южная" агрофирмасында шикәр чөгендерен бөркүгә керештеләр.

### МИЛЛИ КУХНЯ КӨННӘРЕ ҖИТӘ

Шәһәрдә 18 майдан 31 майга кадәр традицион милли кухня көннәре үтәчәк. Кичә милли кухня көннәрен оештыру буенча эшче төркем җәмәгать туклануы предприятиеләре җитәкчеләрен чакырып беренче утырышын үткәрде. Сүз уңаеннан, шәһәрдә 26 ресторан, кафе һәм суши-бар исәпләнә, утырышта аларны чарада актив катнашырга чакырдылар.

### КӨТӘРГӘ КҮП КАЛМАДЫ

1 июньнән старт алачак җәйге каникулларда районда "Заречный", "Нурсан", Чияле Алан" сәламәтләндерү лагерьлары белән бергә мәктәп яны һәм хезмәт, палаткалы лагерьлар да эшләячәк. Хәзерге вакытта аларда балаларны кабул итүгә әзерлек эшләре бара. Гомумән, җәйге каникуллар чорында 2000ләп бала төрле җирләрдә ял итәр, дип планлаштырыла.

# Ул көннәрнең даны онытылмый





З. Әксанова фотосы

ҖИҢҮ ПАРАДЫ МИЗГЕЛЛӘРЕ

**Зур әзерлек белән көткән данлы Җиңү көне – 9 май Нурлатта бөтенхалык бәйрәме булып үтте.**

Традиция буенча, 9 май иртәсендә район башлыгы Равил Кузюров, ТР Дәүләт Советы депутатлары Илгиз Салихов, Рәис Сөләйманов, оешма-предприятие җитәкчеләре, нефтьчеләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары Социалистик Хезмәт Геройлары Зәки Тимерҗанов, Габбас Гыйматдинов, Шәриф Хафизов каберләрен яд иттеләр, якташларыбызны бер минут тынлык һәм дога белән искә алдылар.

Ә иртән-иртүк районның төрле буын вәкилләре яңартылган Хәтер һәм Дан мемориалына ашыкты. Иртәнге сәгать 8дән үк нурлатлыларны һәм шәһәр кунакларын үзәк мәйданда театрлаштырылган мәйданчыклар каршы алды. Почетлы каравыл, Георгий тасмалары, елмаю һәм күз яшьләре аша тыныч тормыш алып килгән якташларыбызны хөрмәтләделәр. Бәйрәм көнендә генә дә үзәк мәйданда 2 меңнән артык Георгий тасмасы таратылды. 10 ел рәттән үткәрелүче акцияне быел да "Бердәм Россия" сәяси партиясенең җирле бүлекчәсе, "Яшь гвардия" яшьләр оешмасы, "Форпост" яшьләр формированиесе уздырды.

– 9 май – гаиләбез өчен иң мөһим бәйрәмнәрнең берсе, – ди нурлатлы Галия Мөхтәсимова. – Безгә тыныч тормыш бүләк иткән ветераннарыбызга рәхмәт. Ә бүген таратылган Георгий тасмасын истәлек буларак кадерләп саклаячакмын.

Бәйрәм көнне мәктәп укучылары оештырган "Безнең рәхмәтне кабул итеп алыгыз" акциясе барышында ветераннарга махсус язылган котлау хатлары да таратылды.

Җиңүнең 70 еллык бәйрәмен Нурлат матураеп, төзекләнеп, бизәнеп каршы алды. Яңартылган үзәк мәйданда халыкның игътибарын фонтан, махсус утыргычлар җәлеп итте. Бәйрәмгә килүчеләрне бай мәдәни программа – "Фронт агитбригадасы" концерты, театрлаштырылган чаралар каршы алды. Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музее, фото һәм китап күргәзмәләре дә кунакларның күңеленә хуш килде. Теләүчеләр "Җиңү символикасы" дип аталган мастер-класста да катнаштылар. Бәйрәмгә махсус бизәлгән раритет машиналар, кул эшләре күргәзмәләре, сәүдә рәтләре, балалар мәйданчыклары нурлатлыларны үзенә тартып торды. Әллә кайдан исе борынны кытыклаган чын солдат боткасы белән сыйланырга теләүчеләр "Хәрби кыр кухнясы" янына җыелды. Блиндаждагы фронт бригадасы янында фоторәсемгә төшәргә һәм хәрби телефон белән сөйләшеп алырга теләүчеләр дә байтак булды. Ветераннарның, тыл хезмәтчәннәренең һәм бәйрәмгә махсус чит шәһәрләрдән кунакка кайтучыларның күңелләрендә хатирәләр яңарды.

– Бәйрәмне бер дә калдырмаска тырышам, - ди Чулпан авылында яшәүче сугыш ветераны Каим Сәмигуллин. – Ел саен парадны карарга махсус киләм.

Советлар Союзы Герое, якташыбыз Михаил Сергеевның кызлары Людмила Юдчиц һәм Галина Куренная да Җиңүнең 70 еллыгы бәйрәменә махсус кайтканнар.

– Бәйрәмне әтиебезнең туган ягында каршы алуыбызга сөенеп туя алмыйбыз, - диләр алар беравыздан район җитәкчелегенә рәхмәт сүзләре җиткереп. – Әтиебезне туган ягында онытмавыгыз, зурлавыгыз өчен баш иябез. Кадерле кешебез туып үскән Тимерлек авылында булу, гимназия укучылары белән очрашулар, бәйрәм программасы безнең күңелдә бик озак сакланачак әле. Нурлат – Россиянең күп шәһәрләренә үрнәк булырлык.

Мәскәүдә яшәүче якташыбыз, полковник Вазыйх Усманов, Нурлатның Мактаулы гражданины, отставкадагы полковник Идеал Галәветдинов Җиңү көнен быел да туган яклары Нурлатта каршы алырга булганнар. Тумышы белән Кизләү авылыннан булган һәм 30 ел гомерен Тамань дивизиясенә биргән Вазыйх Гәрәй улы өчен туган җирендәге бәйрәм парады Мәскәүдәгедән ким түгел.

– Бик матур бәйрәм, – диде Мәскәүдә төп парадта катнашкан якташыбыз. – Туган ягымдагы Җиңү бәйрәме аеруча матур уза.

*(Ахыры 2нче биттә)*


**"ДУСЛЫК"ка ТАШЛАМАЛЫ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫГЫЗ!**

**14 майдан 24 майга кадәр "Әбунә декадасы" кысаларында "Дуслык" район газетасына ташламалы бәяләрдән – почта адресына 486 сум 72 тиеннән, альтернатив газетага 270 сумнан язылырга ашыгыгыз! Сезне почта бүлекчәләрендә һәм редакциябезнең реклама бүлегендә көтәбез.**

## БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

# Ул көннәрнең даны онытылмый

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Бәйрәмнең төп чаралары Хәтер һәм Дан мемориалына веноклар салу белән дәвам итте. Ветераннарның гына түгел, яшь буынның да күңелләрендәге дулкынлану, хөрмәте булып кызыл канәферләр салынды. Тантаналы митинг район башлыгы Равил Кузюровның фронтовикларга, тыл хезмәтчәннәренә, сугыш чоры балаларына, яу кырында ятып калган райондашларыбызга рәхмәт сүзләре белән башланды.



Бәйрәмнең мәртәбәле кунагы – ТР урман хуҗалыгы министры Алмас Нәзиров нурлатлыларга Республика лидеры Рөстәм Миннехановның котлауларын ирештереп, Җиңү язын бүләк иткән буынга рәхмәт сүзләрен җиткерде. Алмас Әминович Җиңүнең 70 еллыгына әзерләнүдә зур өлеш керткән бер төркем предприятие җитәкчеләренә - "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы, ТР Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салиховка Республика Президенты Рөстәм Миннехановның, ТР Дәүләт Советы депутаты, "Агро-Инвест" ИК генераль директоры Рәис Сөләймановка, "Нурлатгаз" ЭПУсы начальнигы Рәшит Хәсәновка ТР Премьер-министры Илдар Халиковның Рәхмәт хатларын тапшырды.

Илгиз Салихов, Нурлат шәһәре хәрби комиссары, полковник Заһир Абдуллин чыгышларында да данлы буынга рәхмәт һәм хөрмәт сүзләре яңгырады.



Яу кырында ятып калган батырлар хөрмәтенә залплар яңгырады, бер минут тынлыкта якташларыбыз искә алынды. Мәйдан буйлап "Җиңү поезды", "Бөек Җиңүнең 70 еллыгы", "Мәскәү өчен көрәш", "Барысы да фронт өчен", заманында Нурлатта оешкан "3624нче эвакогоспиталь", 51нче укчы дивизияне гәүдәләндергән машиналар узды. Парад Балалар сәнгать мәктәбе һәм район мәдәният йортының хореография төркемнәре чыгышлары белән үрелеп барды. Зур парад һәм бәйрәм үзе дә күп коллективларның уртак хезмәте һәм анда һәркем күңел җылысын салырга тырышкан иде. Әлеге чыгышларны караган ветераннар күңелендә 1945 елның 9 мае яңарды. Юбилей елында зур Җиңү Парадына "Үлемсез полк" акциясендә катнашучы 600дән артык шәһәрле кушылды. Шуларның 400е район педагоглары, мәктәп укучылары һәм аграр техникум студентлары иде.




– Бабамның хыялын тормышка ашырам, - диде безгә акциядә катнашучы гимназия укучысы Әмир. – Әниемнең бабасы Фәттах Сәлах улы Камалетдинов гади солдат булса да, аның да парадта катнашасы килгән булгандыр.

Акциядә катнашкан Игорь Литтаның әнисенең бабасы Григорий Ильич Кузнецов Советлар Союзы Герое булган.

– Бабамны Самара өлкәсендә генә түгел, тирә-күрше өлкәләрдә дә хөрмәт иткәннәр. Ул парадта гына түгел, милли бәйрәмнәрдә дә хөрмәтле кунак булган.

Бәйрәмдә ветераннарны мәктәп укучылары, яшь армиячеләр, спортчылар, мәдәният тармагы вәкилләре, "Ветеран" халык хоры, хәрби – интернационалистлар һәм башкалар сәламләде.




Парадтан соң район башлыгы Равил Кузюров ветераннар белән аралашуын шәһәр мәдәният сараенда мул табыннар артында дәвам итте.

Шәһәр үзәгендә башланган бәйрәм, күңел ачулар кичен зур концертка тоташты. Юбилей чын-чынлап халык бәйрәме булып узды. Көне буе барган чаралар шәһәр паркында бәйрәм фейерверкы белән тәмамланды. Бәйрәм көнне шәһәрлеләрнең иминлеген 300 шәхси сак һәм полиция хезмәткәрләре тәэмин итте.

**Зилия ӘКСАНОВА, автор фотолары**

## ХӘБӘРЛӘР

### БӘЙРӘМ ОЧРА

Жиңүнең 70 еллыгын бәйрә
кысаларында узган атнада
башлыгы Равил Кузюров райо
вы – җитәкче постларды эшләгә
Ватан сугышы ветераннары,
Ветераннар советы президиум
залары белән очрашты. Бәйр
быны артында барган очрашу
он башлыгы алда торган олы б
белән котлап, район тормышы
гылышлы планнарга тукталды.
– Җиңүнең 70 еллыгын б
итү кысаларында районда б
эшләр башкарылды, - диде
Әфраимович. – Районда вете
һәм сугышта катнашучыларны
лары – 430 кеше торак шарт
яхшыртуга субсидияләр ал
шәһәрдә ветераннар өчен 5
йорт салынды.
Очрашуда район башлыгы ак
сорауларына җавап бирде,
ның фикер-тәкъдимнәрен һә
тирәләрен дә тыңлады.

### ҖИТӘКЧЕ КОТЛ

Бөек Ватан сугышы ве
Агреппина Сергеева 9 май –
бәйрәме алдыннан район ба
Равил Кузюровның котлаулар
бул итте. Буа районы кызы Агр
Яковлевна сугышка кадәр Е
урман пунктында эшли, 194
Кызыл Армия сафларына
Белоруссия фронтының зени
непоездында ефрейтор дәрәж
хезмәт итә. Белоруссия, Пол
азат итүдә катнаша. 2нче
Ватан сугышы ордены,
һәм "Германияне җиңгән өче
дальләре белән бүләкләнә.
Сугыштан соң да Агр
Сергеева урман пунктында
Тормыш иптәше белән 4 бала
яләп, олы тормыш юлына ба
лар. Бүген исә 7 оныгына ше
итә ветеран.
Очрашу барышында
Әфраимович 91 яшьлек вете
кәефе көр булуына тел шартл
– Юбилей елында бә
көр кәеф белән, бергә карш
бызга шатмын, – диде ул ве
сәламәтлек теләп.

**Зилия ӘК**

### ЧӘЧТАРАШ БУЛАЧА

Нурлат халкының мәшгу
үзәгендә 20 эшсез кеше
раш белгечлеге буенча укул
Апрель азагында башланып
укулар 3 ай дәвам итәчәк, ук
Казан шәһәренең региональ
үзәге белгечләре алып бара.
әйтүләренчә, курслар хезмә
рында чәчтарашларга ихты
булуны исәпкә алып оештыр

**Лилия МӨБАР**

**ЮРИДИК ЯРДӘМ КҮРСӘ**
**21 майда 11.00дән 13.00гә**
Мамык, 14.00дан 16.00га
Якушкино авыл җирлекл
ТР Юстиция министрлыг
Юристлар Ассоциациясе
тырган мобиль мәгълүмать
сультация төркеме гражда
бушлай юридик ярдәм к
Шул ук көнне өлкән с
укучылары өчен "Хокук м
проекты кысаларында лек
нятие дә үтәчәк.

# БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## Якташларны кече Ватан бәйли

**Кече авылларның берсе Петровскида сугышта катнашучылар хөрмәтенә мемориал булдырырга һәм аны зиратка урнаштырырга булганнар.**

Авылда сугышта катнашучы калмаган, поселок үзе дә бетү ягында, туганнары каберләрен яд итәргә кайткан һәркем тыйнак һәйкәлне дә читләтеп уза алмас, дип фикер йөрткәннәр алар.

Ватанны сакларга кечкенә Петровскидан гына да 50 кеше китеп, 12се яу кырында ятып калган. Сугышчы-якташларын искә алырга 9 май көнне аларның Бөекбританиягә, Пермьга, Чиләбегә, Чибәркүлгә, Самарага һәм башка шәһәрләргә таралган балалары, оныклары җыелды. Мемориалны изгеләндерү, Елаур авыл җирлеге башлыгы Галина Кульметьеваның рәхмәтле чыгышы, тыл ветераны Зинаида Курочкинага фронт хаты тапшыру – барысы да дулкынландыргыч халәт тудырды. Отставкадагы хәрбиләр Николай Утенкин һәм Николай Курочкин почетлы каравылга басалар. Бу тантанада Чиләбедә яшәп, якташларын игелекле эшкә туплый алган Валентина Корчагина да катнаша. Туган җирләрендә үз якыннарын искә алырга Бөекбританиядә яшәүче Надежда һәм Колен Марли да кайтканнар.

–Биредә безнең 10 туганыбыз исеме мәңгеләштерелгән. 10сы сугыштан исән-сау кайтканнар,–ди Надежда. 20 еллап инде Англиядә яшәсә дә, кече Ватаны белән арасын өзми ул. Бүген дә башкалар белән бергә мемориалга канәфер чәчәкләре салды, "Үлемсез полк" сафына басты.

Тантаналы митинг салют белән тәмамланды.

**Маргарита ЛИТТА**

## Исемнәре уеп язылган

**8 майда Иске Чаллыда Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан тантаналы митинг үтте.**

Чәчәк-флаглар, сугыш михнәтләрен кичкән бабаларының фотосурәтләрен тоткан укучылар, аларның әти-әниләре, укытучылар иртәнирткүк мемориаль комплекс янына җыелды. Авыл халкын бәйрәм белән район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин котлады.

– Иске Чаллыдан фронтка киткән 507 кешенең исеме комплекска кертелгән, шуларның 325е яу кырыннан кайта алмаган, – диде Әсхәт Касыймович. – Без бу авылның илебезгә Советлар Союзы Герое Николай Кузьмич Синдряковны бирүе белән горурланабыз.

Авылдашларны, ветераннар, тыл хезмәтчәннәрен бәйрәм белән авыл җирлеге башлыгы Юрий Иванов, Иске Чаллы авыл җирлеге Советы депутаты Ирек Камалов та котладылар. Митингка ТР сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннарының иҗтимагый оешмасы әгъзасы Нина Иванова да килгән иде. Ул тумышы белән Кизләүдән, 5-7 сыйныфларны Иске Чаллыда укыган, шуңа да авыл язмышына битараф түгел. Ул чарада катнашучыларны сугыш ветераннары комитетының республика оешмасы исеменнән котлады, сугышсыз беренче көн – 1945 елның 9 мае хатирәләре белән уртаклашты.

Тыл хезмәтчәннәре исеменнән Клавдия Иванова чыгыш ясады. Ул сугыш елларында балаларның, хатын-кызлар һәм картларның басуларда, производствода эшләүләре турында сөйләде. Аннан барысы да сугыштан кайта алмаучыларны бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Бәйрәм чаралары митингтан соң мәдәният йортында дәвам итте: анда ветераннар һәм тыл хезмәтчәннәре өчен концерт программасы әзерләнгән иде.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

## Киекле мемориаллы булды

**Киекле авыл җирлегендә узган бәйрәм чарасы да истәлекле булды.**

Биредә Бөек Ватан сугышында илебез азатлыгы өчен башларын салган, сугыштан кайтып авыр яралардан вафат булган авылдашлар хөрмәтенә Хәтер һәм Дан мемориалы ачылды. Киеклеләрнең шатлыгын уртаклашкан район башлыгы Равил Кузюров чараны зур вакыйга дип атады.

– Бу һәйкәл – халкыбызның батырлык үрнәге, аларга бүгенге буынның олы хөрмәт билгесе булып озак еллар яшәсен, - диде Равил Әфраимович һәм һәйкәлне торгызуда финанс ярдәме күрсәткән "Татнефть" ААҖ генераль директоры Наил Магановка, "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы, ТР Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салиховка олы рәхмәт сүзләре җиткерде.

Чарада катнашкан ТР Дәүләт Советы депутаты, "Нурлатнефть НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов, хәрби комиссар Заһир Абдуллин, районның Ветераннар советы рәисе Разия Садретдинова чыгышларында ветераннар, тыл хезмәтчәннәре, толлар һәм сугыш чоры балалары адресына котлаулар, рәхмәт сүзләре яңгырады.

Киекле авыл җирлегеннән 556 кеше яу кырына киткән, шуларның 242сенә генә әйләнеп кайтырга насыйп булган. Бәйрәмдә ачылган һәйкәлгә 368 кешенең исемнәре уеп язылган. Бүген җирлектә 2 Бөек Ватан сугышы ветераны һәм 74 тыл хезмәтчәне яши. Митингта батырлар бер минут тынлык белән искә алынды.

Бәйрәм чарасы һәйкәлгә веноклар салу һәм мәктәп укучылары катнашындагы парад белән дәвам итте.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## Ветераннарның урыны түрдә

**Иске Әлмәт авыл җирлегеннән 506 кеше сугышка киткән, 274е әйләнеп кайтмаган.**

Бүген шушы авылда туган 4 ветеран исән, аның да икесе генә - Рәшит Гатин һәм Касыйм Морадыймов шушы җирлектә теркәлгәннәр. Бәйрәм митингында аларның урыны түрдә булды һәм һәркем – район башлыгы Равил Кузюров исеменнән чыгыш ясаган аның урынбасары Флюра Ногманова да, авыл җирлеге башлыгы Равил Хисамов та, "Кызыл Шәрык" җәмгыяте вәкиле Рәис Гафиатуллин һәм җәмәгатьчелек вәкилләре дә үз чыгышларын аларга һәм тыл хезмәтчәннәренә, толларга рәхмәт сүзеннән башладылар. Урта мәктәп укучылары парады, аларның музыкаль чыгышы, һәйкәл итәгенә чәчәкләр салу митингка моңсу да, тантаналы да төс бирде.

– Якташларыбыз турында әле дә мәгълүматлар табыла тора, – диде авыл елъязмачысы Җәүдәт Хәйруллин, батырлар исемлегенең тулыланасын искәртеп. Ә бәйрәм мәктәптә дәвам итте. Анда эчтәлекле әдәби-музыкаль композиция, әзерләнгән чәй өстәле, җылы аралашу Җиңүгә өлеш керткән буынга халкыбыз хөрмәте билгесе иде.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

### САН

**Җиңүнең юбилей бәйрәменә район авылларында 7 яңа һәйкәл төзелгән, 15 һәйкәлгә тулы реконструкция ясалган.**



ИСКЕ ЧАЛЛЫ



ПЕТРОВСКИЙ ПОСЕЛОГЫ




КИЕКЛЕ



ИСКЕ ӘЛМӘТ

## ЮБИЛЕЙЛАР МАЕ

**Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтү алдыннан Бөек Ватан сугышы ветераны, Россиянең атказанган икътисадчысы Һавил Рәхимов та котлаулар кабул итте.**

Ул озак еллар икътисад өлкәсендә эшләгән, ә бу көнне ветеранны котларга Федераль казначылыкның ТР идарәсенең 33нче бүлеге начальнигы Ралия Хәсәншина килде. Ул ветеранга җылы теләкләрен җиткерде, чәчәкләр, истәлекле кул сәгате, азык-төлек җыелмасы тапшырды.

Һавил Сабирович фронтка 1943 елның гыйнварендa китә. Карелия фронтында сугыша башлый, Венгрияне, Австрияне азат итүдә катнаша. Венаны азат иткәндә, немец генералын әсирлеккә төшерә. Һавил Рәхимов ике тапкыр яралана. 1946 елда демобилизацияләнә. Аның хезмәт юлы да шанлы уза: колхозда баш бухгалтер, өлкән салым инспекторы, райфо мөдире булып та эшли. Аның сугышчан һәм хезмәт казанышлары төрле бүләкләр белән билгеләп үтелә. "Без ветераннар турында бәйрәмнәрдә генә түгел, һәр көнне кайгыртырга тиеш. Бу – безнең бурычыбыз", – дип саный Ралия Хәсәншина. Шуңа да һәр көнне шалтыратып, ветеранның хәлен белүне гадәткә керткән.


Ә берничә көннән ветеран янә котлаулар кабул итәчәк – 18 майда аңа 90 яшь тула.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ

## “Тимер юлчылар” бистәсе такырая

**Халыклар Дуслыгы йортында, ипотека буенча төзелүче йортта эшләр финиш сызыгына чыкты, ә тимер юлчылар бистәсендә яңа асфальт түшәлә. 11 майда район башлыгы Равил Кузюров әлеге объектлардагы эшләрнең барышын карап чыкты.**




НУРЛАТЛЫЛАР БУ ЮЛГА АСФАЛЬТНЫ БИК ОЗАК КӨТТЕ

Иң элек ул шикәрчеләр бистәсендәге Медведский паркы һәм “Дуслык” скверындагы эшләр-планнар белән кызыксынды. Биредә үсентеләр утырту, аларны карау мәсьәләләрен озакка сузмаска кушты. Халыклар Дуслыгы йортында да ремонт эшләрен 10 июньгә тулысынча тәгәлләргә һәм диаспораларга үз бүлмәләрен җиһазландыруга алынырга кирәк, дигән конкрет бурыч куелды. Подрядчы “НурлатЕвроСтрой” җәмгыятенең мастер-прорабы Андрей Пушкин әйтүенчә, бүген бинага җылылык, ут кертелгән. Хәзер обойлар ябыштыру, агарту, буяу эшләре бара. Аннан территорияне төзекләндерүгә алыначаклар: монда яшелләндерү, Дуслык йортының тирәсен асфальтлау, баскычына плитка түшәү кебек эшләр каралган. Равил Әфраимович, бинаның тирәсен . коймалау, күрсәтмә-такта элү, флагштоклар урнаштыру кебек эшләрне дә озакка сузмаска, диде. Ә бүлмәләрне җиһазлауга исә иганәчеләр дә үз өлешләрен кертә ала. Мисал өчен, ТР Дәүләт Советы депутаты, “ТНП-Зүзәйнефть” җәмгыяте җитәкчесе Шамил Яһудин татар оешмасының почмагын җиһазлауда булышырга вәгъдә бирде инде.

Кариев урамында ипотека буенча төзелүче йортта да эшләр тәгәлләнүгә бара. Подрядчы “Перспектива” җәмгыяте җитәкчесе Әнис Гайнуллин әйтүенчә, 45 фатирлы бу йортны июнь башында файдалануга тапшырачаклар икән.

– Шул көннәрдә обойлар ябыштыра башлыйбыз, һәр фатирга икеоконтурлы газ казаннары куелган, алар кыш чыктылар инде, – диде Әнис Котдусович. Бу йортның территориясендә берничә ишегалдына исәпләнгән балалар мәйданчыгы коруны да планлаштыралар “перспективалылар”.

Нурлатлыларның, бигрәк тә руль артында йөрүчеләрнең ничәмә еллар инде теңкәсенә тигән тимер юлчылар бистәсендәге төп юл да такырая: бүген биредә НУАД яңа асфальт түшәү белән мәшгуль. Линия һәм Куйбышев урамнары буенча сузылган әлеге асфальт юлның озынлыгы 2000 метр тәшкил итәчәк, диде НУАД җитәкчесе Фидаил Садыйков. Район башлыгы Равил Кузюров исә олы юлның читен дә тиешенчә ясарга, бордюрлар куярга һәм һәркайда сыйфатлы материал кулланырга кирәклеген катгый ассызыклады.

Илназ МӨБАРӘКШИН

ЭКОЛОГИЯ

## Законны белмәү җаваплылыктан азат итми

**Узган атнада административ комиссия үз утырышларында экологик службадан, район башкарма комитетының беркетмәләр төзергә вәкаләтлеләреннән, полиция участковыйларыннан кергән 17 материалны карады.**

Административ комиссия утырышына Октябринадан ике кеше килгән иде. Ике очракта да төзекләндерү кагыйдәләрен бозганнар. Муниципаль территориядән такта, вак таш, иске техниканы җыеп алу өчен озак вакыт та кирәкми икән, югыйсә, тик моның өчен район башкарма комитеты уполномоченныеның беркетмә төзүе кирәк булып чыккан. Әмма соңыннан тәүбә итү дә, төзелеш материалын саклауга вакытлыча рөхсәт алу да административ комиссиянең карарына йогынты ясый һәм штрафтан азат итә алмый. Бу авылда яшәүче тагын бер кешедән авылдашлары зарланган булып чыкты: шәхси участогына кермәгән территориядә ул чүплек ясаган.

- Шикаятьләр тагы да керсә, кырысрак җәза бирәчәкбез, - диде табигатьне саклау инспекторы Рөстәм Ногманов. Административ комиссия секретаре Вера Мальцева әйтүенчә, бу очракта кисәтүләр каралмаган, закон бозу бар һәм беркетмә төзелгән икән, штрафны һичшиксез түләргә кирәк булачак. Бу Нурлатта яшәүче гаиләгә дә кагыла, алар да өйләре каршындагы балчык өемен комиссия әгъзаларының визитыннан соң гына җыеп алган.

Кергән материаллар арасында кибет фасадындагы рекламаның законсыз урнаштырылуына кагылышлысы да бар иде. Район башкарама комитетының беркетмәләр төзү буенча уполномоченные, архитектура бүлеге начальнигы урынбасары Лилия Сарбаева әйтүенчә, үзлектән тышкы реклама урнаштыру тыела.

- Моның өчен башта реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт алырга кирәк, - ди ул. – Реклама урнаштыру һәм эксплуатацияләү схемасы буенча урнаштырылырга, аның тышкы кыяфәте архитектур-сәнгати регламентка туры килергә тиеш. Һәм беренче тапкырга билгеләнгән минималь штраф күләме кибет хуҗасына сәүдә ноктасының фасадын да, андагы мәгълүматны да тәртипкә китерергә булышыр, дип уйлыйбыз.

Физик затлар 2000-3000 сум штраф белән котылсалар, предприятие җитәкчеләренең кагыйдәләргә колак салмавы түгәрәк суммага төшә. Мәсәлән, шундый җитәкчеләрнең берсенә карата бер вакытта ике материал кергән: керү юлларының торышы начар булу, машиналар туктап тору өчен урын булдырылмавы һәм койма янында чүп-чар өйгән өчен. Ике беркетмә буенча штраф күләме 30000 сум тәшкил итте. Авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесенә штраф күләме исә күпкә артыграк булды. Аңа территориянең экологик торышы начар булган өчен 200000 сум түләргә кирәк булачак. Моннан тыш, төзелеш чүп-чары да күптәннән ята, биредә тиресне дә автомобиль юлына кадәр диярлек чыгарганнар.

- Мондый штрафны еш билгеләмибез, - ди административ комиссия рәисе урынбасары Лилия Закирова. – Бу очракта сумма экологик кагыйдәләрне кырыс бозган өчен билгеләнде. Ферма калдыкларын юлдан ерак булмаган урыннарга, аншлаг янына ук чыгаралар, үлгән терлекләрне махсус урыннарга илтмиләр, алар кая эләкте – шунда, хәтта елга тирәсендә дә ята. Бу инде гражданнарның экологик куркынычсызлыгын бозу дип санала.

Районда шимбә өмәләре, санитар сәгатьләр дәвам итә. Әмма административ комиссиянең уяулыгы да кимеми...

Сирень СӘМӘРХАНОВА

САН

**17 беркетмәнең күбесе – физик, 3се – вазифаи, 1се юридик затларга карата төзелгән.**

БЕЗНЕКЕЛӘР

### РОСАТОМНЫҢ ЕЛ КЕШЕСЕ – ТУМЫШЫ БЕЛӘН НУРЛАТТАН

**Якташыбыз, 1нче мәктәп чыгарылышы Игорь Жемков узган елда Россия атом тармагындагы иң яхшы хезмәткәрләр арасында “Росатомның ел кешесе-2014” премиясе лауреаты булды. Бу шатлыклы хәбәр белән аның якын туганнары бүлеште.**

Игорь Жемков Димитровградта “ГНЦ НИИАР” җәмгыятенең инженер-физик лабораториясе начальнигы булып эшли. 1012 дәгъвачы арасында тармак премиясенә ул “Галим физик” номинациясендә лаек була. Кандидатларны сайлап алу өч төп юнәлеш буенча узган елның 26 ноябреннән быелның 26 мартына кадәр тармакның барлык предприятиеләрендә дә бара.

Шул рәвешле, Игорь Жемков төрле эшчәнлек юнәлешләрендә зур нәтиҗәләргә ирешүче һәм кече Ватаннарын аннан читтә дә данлаучылар плеядасын дәвам итә.

Маргарита ЛИТТА

## Герой марафоны чыныктыра һәм тәрбияли

**Якташыбыз, Советлар Союзы Герое Анатолий Кузнецов истәлегенә традицион җиңел атлетика кроссы, гадәттәгечә, Геройның туган авылы Каравыл Тавында Кузнецов һәм Билгесез солдат һәйкәлләренә веноклар салудан башланды.**




МАРАФОНЧЫ ЕГЕТЛӘРНЕҢ ФИЗИК ҺӘМ РУХИ КӨЧЛӘРЕНӘ СОКЛАНЫРЛЫК ИДЕ

Җиңү бәйрәме уңаеннан кечерәк кенә митингтан соң, ярышларга старт бирелде. Быел кросста 150дән артык спорт сөюче көч сынашты. Ярышта катнашучыларга Вишневая Полянада туып, бүген Ульян шәһәрендә яшәүче якташыбыз, танылган марафончы, халыкара класслы спорт остасы Михаил Горелов та хәер-фатихасын бирде.

– Еш кына ничек шулкадәр казанышларга ирешә алдыгыз, дип сорыйлар. Һәрчак әйтә килдем: без кыен чорда үстек, авырлыкны җиңә белергә өйрәндек, дим. Менә Кузнецов исемендәге марафонны йөгерү дә авырлыкларны җиңеп, куйган максатыңа ирешергә булыша бит, ә патриотик әһәмиятлелеген әйтеп торасы да юк. Үзем бу марафонда заманында өч тапкыр катнашкан идем, – ди Михаил Анисимович.

Каравыл Тавы-Нурлат марафоны быел 40нчы тапкыр уздырылды. Аны иң беренче булып йөгерүчеләр тәэсирләрен әле бүгенгәчә онытмыйлар.

– 1975 елда башланды аның тарихы. Җиңүнең 30 еллыгы хөрмәтенә җидәү йөгергән идек ул чакта. Күтәртелгән асфальт юл юк иде, Егоркино аша йөгереп Нурлатка кадәр бардык. Бу “батырлыгыбызның” инициаторы ул чактагы „Уңыш” ДСОсының район рәисе Николай Михайлов булды, – дип хатирәләрен уртаклашты тәүге марафонның җиңүчесе Анатолий Саватников. Беренче ярышларда катнашкан районның тагы бер спорт ветераны Аркадий Романов Кузнецов кроссын бер дә калдырмаска тырыша, әлегәчә яхшы формада булуын быел да раслый алды ул. Гомумән, стартка басучылар арасында саллы яшьтәге йөгерешчеләр шактый иде. Мәсәлән, Вишневая Полянадан Михаил Волковка 67 яшь, әмма бу хакта гәп куертырга бер дә яратмый ул. “Кечкенәдән йөгереп үстем. Тик менә гаилә корып җибәргәч, ни сәбәпледер, ташладым. Хәзер менә шул югалган елларны куып тотарга тырышам”, – ди ул уенын-чынын бергә кушып. Хәер, әлләни югалып калмаган икән үзе: заманында спорт мастерлыгына кандидат нормасын да үтәргә өлгергән спортчы.

БӘЙРӘМ БӘЙГЕЛӘРЕ

Быел атлетчылар 16,5 һәм 6,5 чакрымлы дистанциядә көч сынаштылар. Зур марафонны исә соңгы еллардагы традиция буенча, янә Эдуард Жирнов отты. Оештыручылар юбилей марафонында җиңүчеләрне һәм призерларны тантаналы шартларды котлап, бүләкләр тапшырдылар.

Ә көндезге 12дә шикәрчеләр бистәсендә футбол буенча традицион блиц-турнир старт алды. Быел анда “Нурлатнефть” НГДУсы, АТП, “Факел” һәм “Шикәрче” командалары көч сынашты. Нәтиҗәдә, Җиңү Кубогын автотранспортчылар яулады. “Факел” һәм “Шикәрче” командалары II-III урыннарны бүлештеләр. Турнирның бизәге исә район һәм шәһәр спорт ветераннары арасындагы иптәшләрчә матч булды.

Илназ МӨБАРӘКШИН

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

УҢЫШ

## ФОМА КЫЗЫ – ҖИҢҮЧЕ

**Нурлат районының Фома урта мәктәбе 7 сыйныф укучысы Алия Гафурова (җитәкчесе Гөлүсә Әһлиуллина) Intertat.ru электрон газетасы редакциясе Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан укучылар арасында үткәргән “Җиңү ядкәре” бәйгесендә җиңүче дип табылды.**

Әлеге иҗади бәйгедә җиңү яулаган укучыларны бүләкләү тантанасы 7 май көнне Казанда, Татарстан Милли музеенда үтте. Intertat.ru игълан иткән бәйге газета укучыларда зур кызыксыну уяткан. Анда Татарстанның төрле районнарыннан йөздән артык иҗади эш кабул ителгән. Алия “Гаилә ядкәре” номинациясе буенча беренче урын яулаган, ул бәйгегә әнисенең бабасы турында язып җибәргән булган. Сугышта хәбәрсез югалган Кәлимулла бабайларының язмышын оныклары 59 елдан соң гына ачыклый алган. Эзтабарлар аның сугышчы медальонына Тверь өлкәсендә, сугыш вакытында меңләгән солдатлар ятып калган яу кырларында юлыккан. Бабасы җирләнгән туганнар каберлегенә кайбер балалары һәм оныклары барып баш иеп кайткан инде, Алия дә ул җирләрне күрергә хыяллана. Ә бәйгедә җиңүе өчен кызга җиңүче дипломы һәм фотоаппарат бүләк иткәннәр.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМ

## ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ

**Кичә Халыкара шәфкать туташы көне билгеләп үтелде.**

Бәйрәм уңаеннан без сезгә 24 ел гомерен Нурлат үзәк хастаханәсенә багышлаган шәфкать туташы Наталия Петрова турында сөйләргә булдык. Ул балачактан медицина хезмәткәре булу һәм барлык нәни балаларны дәвалау турында хыяллана. 1991 елда Наталия Альбертовна Шентала медицина училищесын бик яхшы билгеләренә тәмамлап, үзенең медицина эшчәнлеген шәһәрнең интенсив терапия палатасында башлый.

– Үз эшемне яратам. Ә тегәлрәге, үзем дәвалаган нәни балаларны, - дип урта-клаша Наталия Альбертовна.

1995 елдан алып эшли башлаган педиатрия бүлегендә эш зур җаваплылык һәм игътибар таләп итә. Һәм Наталия Альбертовна монда бер дигән һөнәрмән!

Ике бала әнисе, яраткан тормыш иптәше һәм искиткеч хуҗабикә дә ул. Буш вакытларын чигү-тегү белән мәшгуль. Ә язын һәм җәен ул гаиләсе белән дачада. Анда ул экзотик агачлар, чәчәкләр үстерү белән мәшгуль.

Коллегалары да аның турында бары яхшы сүзләр генә әйтә.

Елена **ПЕТРОВА**

# Без – тимурчылар

МӘГАРИФ

**Без узган уку елыннан бирле районыбызның данлыклы диңгез флоты офицеры Ислам ага Гыйләҗев гаиләсенә тимур эшенә йөрибез. Алар һәр килүебезне зур түземсезлек белән көтеп алалар.**

Дөрес, без бик ярдәм итәргә теләсәк тә, алар бездән берни дә эшләтмиләр. “Шөкер, балаларыбыз да әйбәтләр, хәлләребезне белеп торалар, тирә-күршеләребез дә игелекле”, - ди Гөлҗиһан апа. Ә без, укучылар, аларның тормыш юлы, үткәннәре белән кызыксынып, үзебез өчен файдалы дәресләр алып китәбез.

Менә бүген дә без Төньяк флотының отставкадагы капитан-лейтенанты һәм отставкадагы милиция майоры, якташыбыз Ислам ага янына ашыга-ашыга килдек. Ислам абый башыннан үткәннәрне исенә төшереп, зур дулкынлану белән сөйләде.

Гыйләҗев Ислам Усман улы 1927 нче елда Биккол авылында дөньяга килә. Кечкенәдән топле акыллы, бик тәртипле һәм максатчан булуы белән башкалардан аерылып тора ул. 1944нче елның 31нче декабрендә хәрби присяга кабул иткәч, 11 ел буе армия сафларында хезмәт итә. 1951нче елларда комсомол эше буенча сәяси бүлекнең җитәкчесе ярдәмчесе була. 1955нче елларда сәяси клуб рәисе булып эшли. Тынгысыз җитәкче үзен бик яхшы яктан гына күрсәтә. Советлар Союзы Хәрби кораллы көчләрендә 1969нчы елдан 1973нче елга кадәр хезмәт итә. Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый.

Ислам Усман улы Төньяк диңгез флотында хезмәт иткәндә, Нурлатка кунакка кайткач, бик чибәр, өстәвенә, уңган да Гөлҗиһан апаны очрата. Алар өйләнешәләр. Ул аны үзе белән Североморскига алып китә, 2 уллары туа. Өлкән улы Равил 20 ел гомерен хәрби хезмәткә багышлаган. Бүгенге көндә хәрби пенсионер.

Ислам ага Нурлатта да киңкырлы эшчәнлек алып бара, 6 ел буе партия райкомының лекторы була. 3 ел шәһәрдә, 3 ел районда шахмат буенча чемпион кала. Тагын 5 ел ветераннар Советы рәисе булып тора ул. “Социалистик ярышта җиңүче” күкрәк билгесе белән бүләкләнә Ислам ага. Без, укучылар, шундый якташыбыз белән чиксез горурланабыз.

Нурлат шәһәре 2 нче урта мәктәбенең 6 А сыйныфы укучылары һәм сыйныф җитәкчесе Рузилә **СӘЙФУЛЛИНА.**

**«Чистополь АВТО»**
**официальный дилер «LADA»**
с 21 апреля по 31 мая 2015 года
реализует автомобили по акциям:
скидка по утилизации 50 000 руб.
скидка по программе LADA Finance 20 000 руб.
Общая сумма скидок на все автомобили LADA составляет 70 000 руб.
Принимаем заказы на поставку автомобилей
LADA, РЕНО, ШЕВРОЛЕ-НИВА,
по рекомендованным ценам заводов-изготовителей.
РТ, г.Чистополь, ул. Валиева, д. 7а.
Подробности акции по тел. 8(84342) 4-15-55.
**Работаем с 8.00 до 18.00, в субботу и воскресенье с 8.00 до 13.00.**
**Организатор акции: ООО «Чистополь-Авто».**

ДОСТАВКА
ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ.
8-937-280-94-84.

***-Профнастил***
***- Сайдинг***
***- Утеплитель***
***- Доборные элементы.***
*Доставка.*
*Выезд на замер - бесплатно.*
*Кредит АО «ОТП Банк».*
***Т.: 8-927-470-29-39.***
*Универсальный рынок,*
*м-н «Инструмент-град».*

Бүгенге көндә “Татарстан Республикасында ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге” коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан гражданнарга торак-коммуналь проблемаларны хәл итүдә булышу мәсьәләләре буенча масштаблы эш алып барыла. Әлеге эшнең төп юнәлешләре булып кайнар линия, халыкка гомуми һәм юридик темалар буенча консультация хезмәтләре күрсәтү тора.
Татарстанда халыкның идарәче компанияләр эше принципларына кагылышлы сораулары күп булу белән бәйле рәвештә, күпфатирлы йортлар Советлары төзелә, алар турыдан-туры оешма җитәкчеләре белән хезмәттәшлек итеп, сорауларны хәл итәчәкләр. Күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең грамоталылыгын арттыру максатыннан, Үзәк белгечләре Казан һәм Татарстан шәһәрләренең күпфатирлы йортлар Советларын укытырга әзер. Укыту өчен средстволар бүлеп бирелгән.
Укыту семинар рәвешендә барачак һәм 12 сәгать дәвам итәчәк. Ул үз эченә торак кодексы нигезләре, энергия белән тәэмин ителеш, юридик практика, күпфатирлы йортлар Советларының идарәче оешмалар белән хезмәттәшлеге мәсьәләләрен үз эченә ала. Семинардан соң барлык катнашучыларга да уку үтү турында сертификатлар, шулай ук методик пособиеләр биреләчәк. Укулар түләүсез.
Үзәк 2015 елда 1000гә якын кешене Коммуналь хуҗалык һәм төзелеш колледжы базасында укытырга әзер.
Колледжның адресы: Большая Шоссейная ур., 14 (3нче кат), җылылык энергетика ресурслары приборлары белән махсус җиһазланган кабинет.
Язылу мәсьәләләре буенча +7 (843) 236-29-97 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.
Адрес: Казан шәһәре, Лобачевский ур., 10в.
Сайт: obcontrolrt.ru
E-mail: obcontrolrt@mail.ru
Реклама

**СРОЧНО ТРЕБУЮТСЯ ОХРАННИКИ**
**ДЛЯ РАБОТЫ НА ПРОМЫШЛЕННЫХ ОБЪЕКТАХ.**
Вахта - две недели через две.
З/п от 850 руб.сутки +питание+проживание+-доставка (бесплатно).
Официальное трудоустройство.
**Т.: 8 937 459 53 00, 8 937 986 76 81**

**Доступные ЗАЙМЫ.**
**Выгодные условия в Нурлате.**
**8-927-455-66-17, ул. Советская, д. 113а.**
**ООО «Импульс-АС».**
**ОГРН 1146320005325.**
http://импульс-ас.рф.

**С 13 по 31 МАЯ**
**В МАГАЗИНЕ «INFINITI»**
**СКИДКА 20% НА ПОСУДУ**
В наличии столовые и чайные сервизы, посуда для приготовления.
**ТЦ «Шифа», 2 этаж, 2-98-54.**

**ТЕЛӘСӘ НИНДИ КАТЛАУЛЫЛЫКТАГЫ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР.**
**8-9600-33-77-55.**

ЖБ КОЛЬЦА.
ДОСТАВКА.
КРАН-МАНИПУЛЯТОР.
Т. 8-927-403-51-99.

***«Дверь-Маркет»***
*АВТОМАТИЧЕСКИЕ ВОРОТА.*
*Рольставни. Откатные ворота.*
*Установка любой сложности.*
*Кредит (АО «ОТП Банк»).*
***8-927-441-65-90,***
***8-937-572-12-54.***

**Теплицы разных размеров окрашенные, оцинкованные.**
Т.: 8-937-579-24-24,
8-987-409-27-06.
Кредит (АО «ОТП Банк»,
АО «Альфа-Банк»).

**«УДАЧА»**
Продолжается набор групп для отдыха в Сочи (Вардане) и Крым (Феодосия) выездом на поезде в июне и июле месяце.
**8-9274-17-17-10.**

**ООО «МИР КРОВЛИ»**
**реализует**
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Парогидроизоляция. Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-72-25.**
**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**

**ПИЛОМАТЕРИАЛЫ**
- Обрезные доски, бруски, необрезная осина 3500 руб.
- Дома из бруса, срубы банные.
- Строительные услуги.
**8-927-441-54-65,**
**8-937-292-82-15.**

**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

**16 мая 2015 года**
1. Гастроэнтерология.
2. Взрослая и подростковая гинекология.
3. Сосудистая хирургия, новый революционный метод при варикозной болезни вен, не требующий госпитализации и наркоза. Помощь при сосудистых звездочках.
4. Кардиология, ревматология.
5. Неврология.
6. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование), исследование сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

**17 мая 2015 года**
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Отоларингология.
5. Аллергология. Иммунология. Решение проблем при бронхиальной астме, аллергических дерматитах, кожных заболеваниях.
6. Андрология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
7. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

**23 мая 2015 года**
1. Гастроэнтерология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Онкогинекология-эндокринология, специализация по менопаузе.

**24 мая 2015 года**
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии, ведение беременности.
2. Диетология.
3. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и з триместра.

Реклама

**КДЦ предоставляет услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».**

Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.
ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г.
ОГРН 1021605358103.
**ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.**

ЦЕМЕНТ.
УСЛУГИ КРАНА-МАНИПУЛЯТОРА.
Т. 8-927-248-52-21.

**ЖАЛЮЗИ.**
Все виды.
Быстро.
Замер и установка бесплатно.
**8-927-672-01-17.**

Мастер
ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА И ДВЕРИ
**- ВХОДНЫЕ И МЕЖКОМНАТНЫЕ ДВЕРИ**
**- МЕТАЛЛИЧЕСКИЕ КОНСТРУКЦИИ** (заборы и доборные элементы)
**- ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА**
**БЕСПРОЦЕНТНАЯ РАССРОЧКА** (без участия банка).
**Тел.: 8-927-434-28-00, 8-927-425-09-59.**
**Ул. Советская, 145 (здание НАЗ).**
Реклама

**ТРЕБУЮТСЯ**
**в организацию с опытом работы не менее 3-х лет:**
**- специалист по оформлению и ведению исполнительной документации (высшее строительное образование, знание программы AutoCAD, Word, Excel)**
**- прорабы с опытом работы в строительстве НГДО**
**- электросварщики 2 уровня НГДО.**
**Т.: 2-81-58, 8-927-442-31-85.**